**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылу белән бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарын һәм аларның гаилә әгъзаларын, торак һәм коммуналь хезмәтләр, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь төзекләндерү өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләмәүләре очрагында, пенялар исәпләүдән азат итү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 58-ФЗ номерлы Федераль законының $9^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылу белән бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарын һәм аларның гаилә әгъзаларын, торак һәм коммуналь хезмәтләр, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь төзекләндерү өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләмәүләре очрагында, пенялар исәпләүдән азат итү тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 31 декабрь
№ ПУ-940

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 31 » декабрендәге
ПУ- 940 номерлы Указы белән
расланды

**Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылу белән бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарын һәм аларның гаилә әгъзаларын, торак һәм коммуналь хезмәтләр, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь төзекләндерү өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләмәүләре очрагында, пенялар исәпләүдән азат итү тәртибе**

1. Әлеге Тәртиптә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылу белән бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарын һәм аларның гаилә әгъзаларын, торак һәм коммуналь хезмәтләр, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь төзекләндерү өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләмәүләре очрагында, әлеге контрактның гамәле туктатылган вакытка кадәр пенялар исәпләүдән азат итү кагыйдәләре билгеләнә.

2. Мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, алар тарафыннан торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләнмәгән очракта, Татарстан Республикасы территориясендәге торакка мөнәсәбәтле рәвештә пенялар түләүдән азат ителә.

3. Әлеге Тәртипне куллану максатларында мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзалары дип аның белән бергә яшәүче хатыны, шулай ук балалары һәм ата-аналары санала. Россия Федерациясе Торак кодексының 31, 69 һәм $91^8$ статьялары нигезендә билгеләнгән очракларда башка затлар мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзалары дип танылырга мөмкин.

4. Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләнмәгән очракта пенялар исәпләүдән азат ителү өчен мобилизацияләнгән гражданнар яисә аларның гаилә әгъзалары тиешле эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы затлар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү ала торган оешмаларга (идарәче оешма, торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы яисә махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы турында федераль закон нигезендә гражданнарның торакка ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында төзелгән башка шундый кооператив, ресурслар белән тәэмин итүче оешма, күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь

төзекләндерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган махсуслаштырылган оешма, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторы (алга таба – оешмалар) гариза бирә.

5. Гариза мобилизацияләнгән граждан, аның гаилә әгъзасы (алга таба – гариза бирүче) яисә аларның вәкиле (алга таба – гариза бирүче вәкиле) тарафыннан ике нөсхәдә язма рәвештә бирелә, аңа түбәндәге документлар теркәлә:

1) мобилизацияләнгән гражданның яисә аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклый торган документның күчермәсе (гариза мобилизацияләнгән гражданның гаилә әгъзасы тарафыннан бирелгән очракта);

2) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүне раслый торган документларның күчермәләре;

3) гаилә әгъзаларының туганлыгын (статусын) раслый торган документларның күчермәләре (мобилизацияләнгән гражданның гаилә әгъзасы тарафыннан гариза бирелгәндә);

4) гариза бирүгә вәкаләтле вәкилнең шәхесен һәм вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләре (гариза бирүче вәкиле тарафыннан гариза бирелгәндә);

5) «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә язма рәвештә бирелгән ризалык.

6. Оешмага документларның күчермәләре төп нөсхәләре белән бергә бер нөсхәдә тапшырыла. Әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы 1 пунктчасында каралган документның төп нөсхәсе бирелми. Әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы 2–4 пунктчаларында каралган документларның төп нөсхәләре, әгәр аларның күчермәләре документларның төп нөсхәсен биргән орган (учреждение) яисә нотариус тарафыннан таныкланган очракта, бирелми.

Документларны кабул итүче зат документларның күчермәләренең төп нөсхәгә туры килү-килмәвен тикшергәннән соң аларны раслый һәм документларның төп нөсхәләрен гариза биргән затка кире кайтара.

7. Гаризаны һәм документларны кабул итүче зат гаризаны кабул ителгән көнне терки һәм гаризаның икенче нөсхәсен гариза биргән затка, аны алу турында билге куеп, кире кайтара.

8. Гариза һәм гаризага теркәп бирелә торган документларның күчермәләре оешмаларга почта аша җибәрелергә мөмкин. Бу очракта документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән тыш) документның төп нөсхәсен биргән орган (учреждение) яисә нотариус тарафыннан таныкланырга тиеш.

9. Гаризалар оешмалар тарафыннан теркәлгән көннән соң өч эш көне дәвамында карала.

10. Мобилизацияләнгән гражданнар яисә аларның гаилә әгъзалары тарафыннан торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләнмәгән очракта пенялар исәпләүдән азат итүдән баш тарту өчен түбәндәге шартлар нигез була:

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплектын бирү;

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларда дөрес булмаган мәгълүматлар бирү.

11. Мобилизацияләнгән граждан аның белән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзелгән датадан торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләнмәгән очракта пенялар исәпләүдән азат ителә һәм әлеге контрактның гамәле туктатылганчы гамәлдә була.

12. Мобилизацияләнгән граждан яисә аның гаилә әгъзалары мобилизацияләнгән гражданның контракты гамәле туктатылу турындагы мәгълүматны оешмага контракт гамәле туктатылган көннән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

13. Мобилизацияләнгән гражданның контракты гамәлдә булган чорда гариза бирү мөмкинлеге булмаган очракта, мобилизацияләнгән граждан яисә аның гаилә әгъзалары контракт туктатылган көннән алты ай дәвамында оешмага, әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган документларны теркәп, контракт гамәлдә булган чорда торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләнмәгән очракта исәпләнгән пеняларны исәптән чыгару турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

14. Техник мөмкинлекләр булганда, оешма һәм гариза бирүче, гариза бирүче вәкиле арасындагы хезмәттәшлек электрон рәвештә алып барылырга мөмкин.